| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Кичкетанского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кичкетаң авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

| | |
|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

| | | |
|---|---|---|
| 19.11.2025 | Кичкетан<br>авылы | № 4 |

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районы «Кичкетаң авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегенең Барҗы-Омга
торак пунктында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм
алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Законның 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Барҗы-Омга торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 30 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2 . Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:
2.1.«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Барҗы-Омга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, (I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекләләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балаларыннан) башка), 2026 елда үзара салым акчасын 900 сум күләмендә кертүгә һәм алынган

акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган   мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?

-  урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, дроссельләр, фонарьлар, электр товарлары һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм алмаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

- торак пункт территориясен төзекләндерү ( чүп үләннәрен чабу, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, ягулык-майлау материаллары,  трактор  өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

- Барҗы-Омга торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (чокырларны ремонтлау өчен юллар сатып алу һәм аларны вак таш белән түшәү  һәм автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, хезмәт  килешүе буенча янгын сүндерү машинасын йөртүчегә түләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

- Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү

«РИЗА»                                                  «КАРШЫ»

2.2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» Кичкетаң авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең Барҗы- Омга торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә 2026 елга гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 30.10.2025 №1 карарны гамәлдән чыгарырга ризамы? «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары үз көчләрен югалткан дип танылды.

«РИЗА»                                                  «КАРШЫ»

1.Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Барҗы-Омга авылы, Клуб урамы, 1нче йорт буенча гражданнар җыенын уздырырга.
4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлегенең башкарма комитетына җыенны оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы И.Н.Җиһангәрәев